**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль район Советы**
**КАРАРЫ**

**2021 елның 1 июле** **№ 47**

**«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 12 декабрендәге 152 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**
**(2018 елның 12 декабрендәге 166, 25.03.2020, № 249 үзгәрешләре белән)**

«Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 26 статьясына үзгәреш кертү хакында» 2013 елның 17 июлендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы кабул ителүгә бәйле рәвештә Кама Тамагы муниципаль районы аерым закон актларының (закон актлары нигезләмәләренең) үз көчләрен югалтуын тану хакында» 2013 елның 17 июлендәге 64-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы **КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы муниципаль хезмәткәрләренең җаваплылыгы турында нигезләмәне раслау хакында» 2012 елның 12 декабрендәге 152 номерлы Кама Тамагы муниципаль районы Советы карарына (2018 елның 12 декабрендәге 166, 25.03.2020 № 249 номерлы үзгәрешләре белән) үзгәреш кертергә, «Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт турында» 2008 елның 17 гыйнварындагы 5-ТРЗ номерлы» сүзләрен «Муниципаль хезмәт турында Татарстан Республикасы кодексы» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) игълан итәргә (бастырып чыгарырга).

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы урынбасары Г.Ә. Габидуллинга йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы Башлыгы,**
**Кама Тамагы муниципаль район Советы рәисе** **Н.А.Вазыйхов**